Татарстан Республикасы

# ЗАКОНЫ

**“Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында” Татарстан Республикасы Законының 6.1 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 28 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында торак төзелеше үсешенә дәүләт ярдәме турында” 2004 елның 27 декабрендәге 69-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 6.1 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 12 (II өлеш); 2005, № 7 – 8; 2008, № 5 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемендә “социаль ипотека системасында” сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 1 өлештә:

а) беренче абзацта “социаль ипотека системасында” сүзләрен төшереп калдырырга;

б) өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“социаль ипотека системасында эшчәнлекне гамәлгә ашыру, шулай ук законнар нигезендә аерым категорияләрдәге гражданнарга торак шартларын яхшырту буенча чаралар күрү өчен махсуслаштырылган оешма (республика коммерциячел булмаган оешма) милкенә.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2013 елның 5 июле
№ 55-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН